**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 август № 598

г. Казань

Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары нигезендә һәм мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә юнәлдерелгән дәүләт ярдәмен күрсәтү, шулай ук мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә Татарстан Республикасының инвестицияләр җәлеп итү ягыннан кызыклы булуы өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары һөнәр белеме бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Югары мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмат системалары мәктәбендә беренче – дүртенче уку елларын укучы студентларга бирелә торган мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантны гамәлгә куярга.

2. Теркәлгән Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\598.docx